МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**__06.04.2020___** Казан шәһәре **№ ____166____**

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга грантлар түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бюджетара башка трансферт бирү турында килешү формасын раслау хакында

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга грантлар бирү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 елның 1 июнендәге 391 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында **боерык бирәм:**

1. Әлеге боерык кушымтасына туры китереп, «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга грантлар түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансферт бирү турында килешү (алга таба – килешү) формасын расларга.

2. Территориаль үсеш идарәсе башлыгына (В.В. Самсонова):

килешүләрнең проектларын әзерләргә һәм аларны Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) башкарма комитетлары белән төзергә;

әлеге Боерык һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 елның 1 июнендәге 391 номерлы карары таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) башкарма комитетлары тапшырган хисаплылыкны тупларга һәм тикшерергә.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан

Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга грантлар бирү турында шартнамә формасын раслау турында» 2018 елның 14 маендагы 218 номерлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары Н.В.Кондратовка йөкләргә.

**Министр** **М.Р. Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының
2020 елның 6 апрелендәге
166 номерлы боерыгы кушымта

Форма

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга грантлар түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бюджетара башка трансферт бирү турында килешү

Казан шәһәре
«___» _________________ 20__ ел. № ______________

Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак, алга таба «Министрлык» дип аталучы муниципаль берәмлек бюджетына бюджетара башка трансферт бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы,________________________________________
____________________________________________________________исеменнән,
(Министрлык җитәкчесенең яисә ул вәкаләт биргән затның вазыйфа атамасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)
________________________________________________________ нигезендә эш итә,
(хакимият органы турында нигезләмә, ышаныч кәгазе, боерык яки башка документ)
бер яктан һәм ___________________________________________________________,
(муниципаль район, шәһәр округы Башкарма комитеты атамасы)
алга таба «Вәкаләтле орган» дип атала, _________________________________________
______________________________________________________________ исеменнән,
(муниципаль район, шәһәр округы Башкарма комитеты җитәкчесенең яисә ул вәкаләт биргән затның вазыйфа атамасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)
________________________________________________________ нигезендә эш итә,
(устав, ышаныч кәгазе яки башка документ)
икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталып, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, ____________________________________
_______________________________________________________________________,
(тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы яки тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы законы)
____ елның «__» _________ ____ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 1 июнендәге 391 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында нигезләмә (алга таба – «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында нигезләмә) һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ___ елның _________ _______ номерлы карары нигезендә түбәндәгеләр хакында әлеге Килешүне төзеде.

## I. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешүнең предметы 20___ елда «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга грантлар түләүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә, Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнарын классификацияләүнең түбәндәге кодлары: Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүче коды ___________, бүлек __________, бүлекчә __________, максатчан статья ________, чыгымнар төре ____________ буенча, «__________
_____________________________________________________________________»
(Татарстан Республикасы дәүләт программасының аталышы)
Татарстан Республикасы дәүләт программасының «___________________________
(ярдәмче программа)
______________________________________» ярдәмче программасы буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан _____________________________________ бюджетына
(муниципаль район, шәһәр округы бюджеты)
бюджетара башка трансферт (алга таба – Бюджетара башка трансферт) бирүдән гыйбарәт.

## II. Бюджетара башка трансферт бирүне финанс белән тәэмин итү

2.1. Бюджетара башка трансферт Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә әлеге Килешүнең I бүлегендә күрсәтелгән максатка түбәндәге күләмдә бирелә:

20___ елда __________ (_____________________) сум ___ тиен.
(сумманы хәрефләр белән язарга)

## III. Бюджетара башка трансферт бирү шартлары һәм тәртибе

3.1. Бюджетара башка трансферт «_______________________________________
_____________________________________________________________________»
(Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законының аталышы)
____ елның «___ » ________________ _____ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә (финанс елына һәм 20__ - 20___ еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлеге) һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак Министрлыкка финанс елына җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3.2. Татарстан Республикасы бюджетыннан Бюджетара башка трансферт Федераль казначылык идарәсенең Татарстан Республикасы буенча территориаль

органындагы вәкаләтле органның муниципаль берәмлекләр бюджетлары акчалары белән операцияләрне исәпкә алу өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә ачылган шәхси счетына әлеге Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән күләмдә, әлеге Килешү төзелгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 10 көнлек чорда күчерелә.

3.3. Вәкаләтле орган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга грант бирүгә бюджетара башка трансфертны тота.

## IV. Якларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Министрлык бурычлы:

4.1.1. әлеге Килешүдә билгеләнгән Бюджетара башка трансферт бирү шартлары Вәкаләтле орган тарафыннан үтәлгән очракта, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак Министрлыкка бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Бюджетара башка трансферт бирүне тәэмин итәргә;

4.1.2. әлеге Килешүнең 3.2 пункты нигезендә күрсәтелгән Вәкаләтле орган счетына Бюджетара башка трансферт күчерелүен тәэмин итәргә;

4.1.3. Вәкаләтле орган тарафыннан тапшырыла торган документларны тикшерергә;

4.1.4. әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган әлеге Килешүнең 2 нче кушымтасы нигезендә Бюджетара башка трансферттан файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткечен билгеләргә;

4.1.5. әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган бу Килешүнең 3 нче кушымтасында билгеләнгән форма буенча, әлеге Килешүнең 4.3.3 пункты нигезендә тапшырылган нәтиҗәлелек күрсәткеченә ирешү турындагы хисап белешмәләре нигезендә, әлеге Килешүнең 4.1.4 пункты нигезендә Министрлык тарафыннан билгеләнгән Бюджетара башка трансферттан файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткеченә ирешү йөкләмәләрен исәпкә алып, Вәкаләтле органның Бюджетара башка трансферттан файдалануын бәяләргә;

4.1.6. Бюджетара башка трансферт бирү тәртибенең, максатларының һәм шартларының һәм әлеге Килешүдә һәм «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәдә билгеләнгән башка йөкләмәләрнең Вәкаләтле орган тарафыннан үтәлүен тикшереп торырга;

4.1.7. Министрлык Бюджетара башка трансферт бирү тәртибенең, максатларының һәм шартларының һәм әлеге Килешүдә һәм «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәдә билгеләнгән башка йөкләмәләрнең Вәкаләтле орган тарафыннан бозылуын ачыклаган очракта яки бу факт(лар) турында дәүләт финанс контроле органыннан мәгълүмат алынганда, шул исәптән Вәкаләтле орган тарафыннан әлеге Килешү нигезендә тапшырылган документларда төгәл булмаган мәгълүматлар күрсәтелгән очракта, Вәкаләтле органга, таләптә күрсәтелгән күләмдә һәм срокларда, Бюджетара башка трансфертны Татарстан Республикасы бюджетына кайтару турында таләп (алга таба – таләп) җибәрергә;

4.1.8. әлеге Килешүнең 4.4.2 пункты нигезендә Вәкаләтле орган мөрәҗәгате алынганнан соң 10 эш көне эчендә әлеге Килешүнең үтәлешенә бәйле мәсьәләләр буенча Вәкаләтле органга аңлатмалар җибәрергә;

4.1.9. Россия Федерациясенең бюджет законнарында, «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәдә һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка йөкләмәләрне үтәргә.

4.2. Министрлык хокуклы:

4.2.1. бу Килешүнең шартларын үзгәртү турында, шул исәптән әлеге Килешүнең 4.4.1 пункты нигезендә Вәкаләтле орган тарафыннан җибәрелгән мәгълүматлар һәм тәкъдимнәр нигезендә дә, Бюджетара башка трансферт күләмен киметү, шулай ук әлеге Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән файдаланылмаган бюджет йөкләмәләре лимитлары булганда һәм әлеге үзгәрешкә Вәкаләтле органнан финанс-икътисадый нигезләүне үз эченә ала торган мәгълүмат тапшырылуы шарты белән, Бюджетара башка трансферт күләмен арттыру турында карар кабул итәргә;

4.2.2. Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә, Вәкаләтле органнан Бюджетара башка трансфертның калган өлешен юнәлдерү зарурлыгын нигезли торган документлар алынган көннән башлап биш эш көне узганчы әлеге Килешүнең I бүлегендә күрсәтелгән максатларга 20___ елда файдаланылмаган Бюджетара башка трансфертның калган өлешен 20___ елга юнәлдерү зарурлыгы булуы турында карар кабул итәргә һәм Бюджетара башка трансфертның әлеге калдык өлешен агымдагы финанс елында күрсәтелгән максатларга Бюджетара башка трансфертның калган өлешеннән артмаган акча күләмендә Вәкаләтле органга кайтарырга;

4.2.3. әлеге Килешүнең 4.1.6 пункты нигезендә Бюджетара башка трансферт бирү тәртибенең, максатларының һәм шартларының һәм әлеге Килешүдә һәм «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәдә билгеләнгән башка йөкләмәләрнең Вәкаләтле орган тарафыннан үтәлүенә контрольлек башкару өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны Вәкаләтле органнан сорарга.

4.2.4. Россия Федерациясенең бюджет законнары һәм «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмә нигезендә башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

4.3. Вәкаләтле орган түбәндәге йөкләмәләрне ала:

4.3.1. әлеге Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашыру буенча йөкләмәләрне үтәү;

4.3.2. әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган әлеге Килешүнең 2 нче кушымтасында билгеләнгән чараны гамәлгә ашыру кысаларында Бюджетара башка трансферт бирүнең нәтиҗәлелек күрсәткеченә ирешү;

4.3.3. әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган бу Килешүнең 1 нче кушымтасына ярашлы форма буенча Министрлыкка Бюджетара башка трансферттан файдалану турында хисап, әлеге хисап белешмәләрен раслый торган документларның таныкланган күчермәләрен һәм фотоматериалларны тиешле рәвештә кушымтага теркәп, әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган бу Килешүнең 3 нче кушымтасына ярашлы форма буенча Бюджетара башка трансферттан файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткеченә ирешү турында хисап һәм әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган бу Килешүнең 4 нче кушымтасына ярашлы форма буенча, хисап чорында чыгымнар тотуны раслый торган документларны теркәп, Бюджетара башка трансферттан файдалану турында хисап тапшыру;

4.3.4. Бюджетара башка трансферт акчаларының әлеге Килешүнең I бүлегендә күрсәтелгән чарага максатчан һәм нәтиҗәле файдаланылуын тәэмин итү;

4.3.5. Министрлык таләбе буенча, әлеге таләп алынган көннән башлап биш эш көне эчендә әлеге Килешүнең 4.1.6 пункты нигезендә Бюджетара башка субсидия бирү тәртибе, максатлары һәм шартлары үтәлүенә контрольлек башкару өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны җибәрү;

4.3.6. Бюджетара башка субсидия бирү тәртибе, максатлары һәм шартлары үтәлүенә тикшерүләр уздырганда Министрлыкка һәм дәүләт (муниципаль) контрольлек органнарына каршы килмәү;

4.3.7. әлеге Килешүнең 4.1.7 пункты нигезендә Министрлыктан таләп алынган очракта:

4.3.7.1. әлеге таләптә билгеләнгән вакыт эчендә Бюджетара башка трансферт бирүнең тәртибе, максатлары һәм шартлары бозылу факт(лар)ын бетерү;

4.3.7.2. әлеге таләптә билгеләнгән күләмдә һәм вакыт эчендә Бюджетара башка трансфертны Татарстан Республикасы бюджетына кайтарып бирү;

4.3.7.3. әлеге Килешү нигезендә Министрлыкка тапшырыла торган белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын тәэмин итү;

4.3.8. хисап елыннан соң килгән финанс елының 1 гыйнварына кадәр файдаланылмаган Бюджетара башка трансферт акчаларының калган өлешен Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән срокларда Татарстан Республикасы бюджетына кайтару;

4.3.9. Россия Федерациясенең бюджет законнары һәм «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмә нигезендә башка йөкләмәләрне гамәлгә ашыру.

4.4. Вәкаләтле орган хокуклы:

4.4.1. бу Килешүгә үзгәрешләр кертү турында, шул исәптән Бюджетара башка трансфертның күләмен үзгәртү зарурлыгы билгеләнгән очракта да, әлеге үзгәрешкә финанс-икътисадый нигезләүне үз эченә ала торган мәгълүматларны теркәп, Министрлыкка тәкъдимнәр җибәрергә;

4.4.2. бу Килешүне үтәүгә бәйле рәвештә аңлатмалар алу максатында Министрлыкка мөрәҗәгать итәргә;

4.4.3. әлеге Килешүнең 4.2.2 пункты нигезендә Министрлык Бюджетара

башка трансфертның тиешле калдык өлешен кайтарып биргән очракта, әлеге Килешү нигезендә алынган Бюджетара башка трансфертның файдаланылмаган өлешен (булган очракта) 20___ елда шушы Килешүнең I бүлегендә күрсәтелгән максатларга туры китереп түләүләргә юнәлдерергә;

4.4.4. Россия Федерациясенең бюджет законнары һәм «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмә нигезендә башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

## V. Якларның җаваплы булуы

5.1. Әлеге Килешү шартларын үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен Яклар Россия Федерациясе законнарында каралганча җаваплы була.

5.2. Вәкаләтле орган әлеге Килешүдә каралган йөкләмәләрнең теләсә кайсын бозган, әлеге Килешүдә каралган документларны һәм хисапларны тапшырмаган яки вакытында тапшырмаган очракта, әлеге Килешүнең 4.1.4 пункты нигезендә билгеләнгән Бюджетара башка трансферттан файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткеченә ирешмәгән, төгәл булмаган мәгълүматлар тапшырган очракта, Министрлык, белдерү алынган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек срокта Бюджетара башка трансферт акчаларын кире кайтаруны таләп итеп, әлеге Килешүне вакытыннан алда өзү турында белдерү җибәрү юлы белән, бу Килешүне өзәргә хокуклы.

5.3. Хисап финанс елында файдаланылмаган Бюджетара башка трансферт акчалары калган очракта, акчаның калдык өлеше хисап елыннан соңгы елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтарып бирелергә тиеш.

5.4. Хисап елыннан соңгы елның 1 гыйнварына файдаланылмаган Бюджетара башка трансферт акчаларының калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемենә күчерелмәсә, әлеге акчалар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Субсидияләр, субвенцияләр һәм максатчан билгеләнеше булган бюджетара башка трансфертлар формасында алынган бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдык өлешләрен Татарстан Республикасы бюджеты керемենә түләттерү тәртибен раслау турында» 2013 елның 4 июлендәге 21-53-35 номерлы боерыгында билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә түләттерелергә тиеш.

## VI. Контроль һәм хисаплылык

6.1. Вәкаләтле орган Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

6.1.1. 20___ елның 1 июленә кадәрге срокта әлеге Килешүнең 1 нче кушымтасына ярашлы форма буенча әлеге Килешүнең 4.4.3 пункты нигезендә Бюджетара башка трансферттан файдалану турында хисап.

6.1.2. 20___ елның 15 гыйнварына кадәрге срокта әлеге Килешүнең 3 нче кушымтасына ярашлы форма буенча бу Килешүнең 4.3.3 пункты нигезендә

Бюджетара башка трансферт бирүнең нәтиҗәлелек күрсәткеченә ирешү турында хисап.

6.1.3. хисап чорыннан соң килгән айның 7 нче көненә кадәрге срокта квартал саен әлеге Килешүнең 4 нче кушымтасына ярашлы форма буенча бу Килешүнең 4.3.3 пункты нигезендә Бюджетара башка трансферттан файдалану турында хисап.

6.1.4. Министрлык таләбе буенча, әлеге таләп алынган көннән башлап биш эш көне эчендә, әлеге Килешүнең 4.1.6 пункты нигезендә Бюджетара башка субсидия бирү тәртибе, максатлары һәм шартлары үтәлүенә контрольлек башкару өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат.

6.2. Бюджетара башка трансферт акчаларын максатчан тотуга контрольлек Министрлык тарафыннан әлеге Килешүнең 6.1 пунктында күрсәтелгән хисаплар нигезендә гамәлгә ашырыла.

## VII. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

7.1. Әлеге Килешү Яклар аңа кул куйган вакыттан башлап үз көченә керә һәм 20___ елның 1 июленә кадәр гамәлдә була.

7.2. Килешүнең гамәлдә булу вакытын туктату Вәкаләтле органны килешүнең 4.3.3, 4.3.5, 6.1.1, 6.1.2 һәм 6.1.3 пунктлары нигезендә хисаплылык тапшыру йөкләмәләреннән азат итми.

## VIII. Башка шартлар

8.1. Әлеге Килешүгә теләсә нинди үзгәрешләр һәм өстәмәләр алар тиешенчә язма рәвештә төзелгән очракларда һәм Якларның вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланганнан соң гына гамәлгә кергән була.

8.2. Әлеге Килешүне үтәү барышында ихтимал барлык бәхәсләр һәм ризасызлыклар Яклар тарафыннан сөйләшүләр алып бару һәм консультацияләр юлы белән хәл ителә.

8.3. Сөйләшүләр алып бару һәм консультацияләр юлы белән бәхәсләрне хәл итү мөмкин булмаган очракта, бәхәсләр Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә суд аша хәл ителергә тиеш.

8.4. Әлеге Килешү бертигез юридик көчкә ия өч нөсхәдә төзелде, Министрлык өчен – ике нөсхәдә, берсе – Вәкаләтле орган өчен.

8.5. Вәкаләтле орган Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Грант бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен, шулай ук әлеге Килешүне үтәүгә тикшерүләр уздырылуына ризалык бирә.

## IX. Якларның юридик адреслары һәм реквизитлары

| | |
|---|---|
| Министрлыкның атамасы<br>Юридик адресы:<br>Банк реквизитлары:<br>Банк учреждениесенең аталышы<br>БИК<br>к/с<br>И-х/сч<br>Шәхси счет:<br>ИНН/КПП<br>ОГРН<br>ОКТМО | Вәкаләтле органның атамасы<br>Юридик адресы:<br>Банк реквизитлары:<br>Банк учреждениесенең аталышы<br>БИК<br>к/с<br>И-х/сч<br>Шәхси счет:<br>ИНН/КПП<br>ОГРН<br>ОКТМО |

Якларның имзалары

| Министрлык: | Вәкаләтле орган: |
|---|---|
| _______________/________________________<br>(имза) (фамилия, исем, ата исеме) | _______________/________________________<br>(имза) (фамилия, исем, ата исеме) |

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга грантлар түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бюджетара башка трансферт бирү турында _________ ____ номерлы килешүгә 1 нче кушымта

Форма

Расланды
Республикасы икътисад министры урынбасары
___________/___________

Бюджетара башка трансферттан файдалану турында
хисап

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга грантлар түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан Бюджетара башка трансферт бирү турында 20___ елның «__»______ ______ номерлы Килешү нигезендә бирелгән Бюджетара башка трансфертны тоту турында раслыйм.

| Территориаль иҗтимагый үзидарә атамасы | Чараларның, башкарылган эшләрнең, күрсәтелгән хезмәтләрнең аталышы, аларны үткәрү срогын һәм аларда катнашучыларны (башкаручыларны) да күрсәтеп | Саны катнашучылар, кеше | Чараларның, эшләрнең башкарылуын яки хезмәтләрнең күрсәтелүен раслый торган документларның исемнәре һәм реквизитлары | Барлыгы, шул исәптән бюджеттан тыш акчалар, сум |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | ҖӘМГЫСЕ: |

Хисапка әлеге хисап мәгълүматларын раслый торган документларның тиешенчә расланган күчермәләре һәм фотоматериаллар теркәлә ___ биттә ____ нөсхәдә.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
________________ муниципаль район (шәһәр округы) – Вәкаләтле орган
Фамилия, исем, ата исеме: _____________ Имза __________________________
«______» __________20___ ел.

**Финанс-бюджет палатасы рәисе**
______________ муниципаль район (шәһәр округы) – Вәкаләтле орган:
Фамилия, исем, ата исеме: _____________ Имза __________________________
«_____»_____________20___ ел.

**Территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчесе**
______________ муниципаль район (шәһәр округы)

| Тәртип саны | Территориаль иҗтимагый үзидарә атамасы | Фамилия, исем, ата исеме | Имза | Дата |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

| Министрлык: | Вәкаләтле орган: |
|---|---|
| _______________/_______________________<br>(имза) (фамилия, исем, ата исеме) | _______________/_______________________<br>(имза) (фамилия, исем, ата исеме) |

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга грантлар түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бюджетара башка трансферт бирү турында __________ _____ номерлы килешүгә 2 нче кушымта

Бюджетара башка трансферттан файдаланунын нәтиҗәлелек күрсәткече

| Чараның атамасы | Күрсәткечнең атамасы | ОКЕИ буенча үлчәү берәмлеге | | Күрсәт-кечнең план билгесе | Күрсәткечкә ирешү планлашты-рылган срок |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Атама-сы | Коды | | |
| 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Татарстан Республикасының территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерү | Конкурста җиңүчеләргә һәм призерларга түләнгән грантлар саны | Бер. | | | |

| Министрлык: | Вәкаләтле орган: |
|---|---|
| ______________/______________________<br>(имза) (фамилия, исем, ата исеме) | ______________/______________________<br>(имза) (фамилия, исем, ата исеме) |

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга грантлар түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бюджетара башка трансферт бирү турында ___________ _____ номерлы килешүгә 3 нче кушымта

Форма

Расланды
Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары
___________/___________

20___ елның __ ________ карата Бюджетара башка трансферттан файдаланунының нәтиҗәлелек күрсәткеченә ирешү турында хисап

Вәкаләтле органның атамасы ____________________________________________________
Ешлылык: еллык

| т/с | Чараның атамасы | Күрсәткеч атамасы | Күрсәт-кечнең план билгесе | Хисап датасына ирешелгән күрсәткеч | Планны үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

Хисап кабул ителде:

Вәкаләтле орган җитәкчесе
(вәкаләтле зат)
____________________________________
*(вазыйфа, имза, тулы имза)*

Башкаручы ______________________________
_______________________________________
*(вазыйфа, фамилия, исем, ата исеме, телефон)*

«___» _____________ 20 ___ел.

Территориаль үсеш идарәсе башлыгы
____________________________________
*(имза)*

Муниципаль берәмлекләрне үстерү бүлеге башлыгы
____________________________________
*(имза)*

«___» _____________ 20 ___ел.

| Министрлык: | Вәкаләтле орган: |
|---|---|
| _______________/_______________________<br>(имза) (фамилия, исем, ата исеме) | _______________/_______________________<br>(имза) (фамилия, исем, ата исеме) |

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсында җиңүчеләргә һәм призерларга грантлар түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бюджетара башка трансферт бирү турында __________ _____ номерлы килешүгә 4 нче кушымта

Форма

Расланды
Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары
___________/___________

20 елның «___» ________ карата Бюджетара башка трансферттан файдалану турында хисап

Вәкаләтле органның атамасы _______________________________________________
Ешлыгы: кварталлык
Үлчәү берәмлеге: сум (икенче дистә билгесенә кадәр төгәллек белән)

| Күрсәткечнең атамасы | Суммасы | | Чыгымнарны тотуны раслый торган документларның реквизитлары |
|---|---|---|---|
| | Хисап чоры | Ел башыннан бирле арта баручы йомгагы белән | |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Агымдагы финанс елы башына Бюджетара башка трансфертның калдык өлеше, барлыгы | | | |
| шул исәптән:<br>расланган ихтыяҗ | | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кайтарып бирелергә тиеш | | | |
| Күчкән Бюджетара башка трансферт акчалары, барлыгы | | | |
| Хисап датасына касса чыгымнары, барлыгы | | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акчалар, барлыгы | | | |
| шул исәптән:<br>максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган | | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылганы, барлыгы | | | |
| шул исәптән:<br>агымдагы финанс елы башына Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акчаларның калган өлеше | | | |
| Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле, торгызылган акчалар | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Алардан: максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган | | | |
| Хисап чоры ахырына Бюджетара башка трансфертның калган өлеше, барлыгы | | | |
| шул исәптән: Татарстан Республикасы бюджеты кире кайтарылырга тиеш | | | |

Хисапка әлеге таблицаның 4 нче графасында санап үтелгән чыгымнарны гамәлгә ашыруны раслый торган документларның тиешенчә расланган күчермәләре теркәлә.

Вәкаләтле орган ________________ _________ __________________________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза)

Башкаручы ________________ __________________________ _______________
(вазыйфа) (фамилия, исем, ата исеме) (телефон)

«___» __________ 20__ ел.

| Министрлык: | Вәкаләтле орган: |
|---|---|
| _______________/_______________________<br>(имза) (фамилия, исем, ата исеме) | _______________/_______________________<br>(имза) (фамилия, исем, ата исеме) |